Викимедиа җәмгыятенең татар телле катнашучылары төркеме

ВИКИМЕДИА РУ



ФАДН России

# Россия вики-волонтёрларының Татарстан Республикасы институтлары белән хезмәттәшлеге

Онлайн форум-диалог «Тел сәясәте: россиякүләм экспертиза», Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык (ФАДН) чарасы, 18.12.2020

Фәрһад Фәткуллин, материаллар - **w.wiki/qT8**

Россия Федерациясенең Ватандашлар Кодексының 1286 номерлы матдәсе нигезендә
Creative Commons Attribution-Share Alike 4.0 International ирекле лицензиясе шартлары буенча таратыла


# Проект максатлары

Цифрлы чорда татар теленең саклanылуын һәм үсешен тәэмин итү

Үрнәгебездә Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка халыкларны да гамәлләргә илһамландыру

# Ә сез кем?


* 6 телдә уйлыйм, сөйлим, язам
* 2000 елдан бирле түләүле синхрон тәрҗемәчесе
* менеджмент бакалавры
* мәдәниятара коммуникацияләр специалисты
* инглиз телендә Риск-менеджмент укытуым тәҗрибәсе бар
* Арктика һәм Антарктидада булмадым
* 2018 елгы Ел Викимедиачысы
*«Россия халыклары телләрендәге Википедияләр» проектының сәркәтибе
* Татарстан Республикасы Президенты буендагы татар телне саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе әгъзасы (НП «Викимедиа РУ» исеменнән)



Фәрһад Фәткуллин, 1979 т.е.
Казан

frhd@narod.ru
+7 9274 158066
frhdkazan @ Wikipedia

# Вики-волонтёрлык?






*«Һәрбер кеше бар булган гыйлемгә ирекле килеш ирешә алган дөньяны китерегез күз алдыгызга. Гамәлләребез нәкъ шуңа юнәлгән.»*

# Чыгыш максаты

Википедия
*Ирекле энциклопедия*

tt.wikipedia.org
т.к. 15.09.2003

* Тел энтузиастларының Татарстан иҗтимагый институтлары яклаган инициативасы тәҗрибәсе белән уртаклашу

* Күршеләрне цифрлы чорда телләренең чәчәк атуларын тәэмин итә алулары өчен үз Википедияләре бергән мөмкинлекләрен куллануга өндәү

# Диагноз?

Дөньяның 7000+ теленнән 5%-ннан киме генә цифрлы чорда яшәүне дәвам итә алуга ия:

«***үз Википедиясе булмаганнарының тотрыклы яшәүгә шанслары юк.***»


*Телләрнең цифрлы үлеме, Андраш Корнай һ.б., 2013*

*«Китмибез!» Габдулла Тукай, 1907*

# Интернетны үзебез белән тутыру

*Кулланучыга керәге:*

** мәгълүматка ирешү*
** табылу тизлеге*
** иң соңгы хәле һәм тулылыгы*
** контекстуаль актуальлек*
** үзләштерү уңайлылыгы*



# Гугл ярдәме тисен!?

- Иптәшләре кем икән?

- Википедия (Wikipedia)
һәм дә Викимәгълүмат (Wikidata).
Айрылгысыз диярлек!

- Шәп! Болар белән дуслашыйм әле!

# Ни эшләп була?



«Википедия Уэльсның мәгариф системасы үзәгендә» видео-доклады

Викимедиа күптеллелек конференциясе 2020 w.wiki/roM

*https://cy.wikipedia.org/*
*132 133 мәкалә*

«Уэльс телендәге Википедия берүзе валлий телен саклый алмас, тик соңгысының XXI гасырда сакланылуы һәм үсеше өчен бу телдә бер туктамыйча яңарып торучы ирекле универсаль энциклопедиянең үсешен һәм чәчәк атуын тәэмин итүдән яхшырак нигез була алмый» *русча w.wiki/XKD*

# Актуальмы?

Кеше аңлаган телдә әйткәндә, аның башына мөрәҗәгать итәсең.

Туган телендә сөйләгәндә исә — йөрәгенә.

Нельсон Мандела

** РФ Президенты йөкләмәләре җыентыгы*
** Чит ил эшләре министрлыгы, Федерация Советы, төбәкләр җитәкчелеге, Иҗтимагый Пулат, Президент грантлары фонд*
** Ирекле лицензияләр ГК 1286 (2014 ел)*
** РФ Фәннәр академиясе, ЮУЙ, китапханәләр, һ.б.*

# Стратегия

«Кызыксындырган телләрдә һәм темалар буенча иҗтимагый яктан файдалы публик контентны эффектив килеш тудыру, аның Википедиягә эләгүен һәм дөнья буенча таралуын тәэмин итү»



Төрле территориаль-мәдәни феноменнарының Википедиядә яктыртылуы (май 2019)

Юл картасы: *w.wiki/fXk*

# Бергә көчлерәк




**«Россия халыклары телләрендәге Википедияләрне үстерү»**

*Милләтеңә һәм аның теленә изге киләчәк телисеңме?*
*Үз кулларыңа алчы!*
*Ничек?*
*Бу телдәге Википедиягә кертем ясарга, тупланган белем һәм тәҗрибәң белән уртаклашырга башла!*
***w.wiki/8eS***

*Россия вики-волонтёрларының Татарстан институтлары белән хезмәттәшлеге* — w.wiki/qT8

# РФ халыкларының вики-дуслыгы



# Кайдан башларга?

*“Татарстанга — әлбәттә татарчадан!*
*Тат.Википедия Татнетның Топ-5 тә.*

*Берәр телдә*
*сөйләшүчеләр саны югарырак булуы белән*
*Википедия бүлеге дә*
*гадәттә киңрәк үсеш ала*
*һәм*
*кагыйдәләр һәм күзәтүчеләр саны, нигез*
*таләпләр, җәмгыятьнең гадәтләре һ.б.*
*катгыйрак була*

# Хәзер кайда сез?

| Күрсәткеч | Инглизчә ВП | Русча ВП | Татарча ВП |
|---|---|---|---|
| Мөрәҗәгатьләр (көнгә, ноябрь) | 265,589,444 | 27,911,880 | 9,570 |
| Баш биткә мрҗгтьлр (көнгә, ноябрь) | 6,578,404 | 457,763 | 665 |
| гаджетлардан (көнгә, ноябрь) | 76,241,259 | 9,196,686 | 1,776 |
| Мәкаләләр (16.12) | 6,209,289 | 1 683 458 | 236 725 |
| Сүзләр (16.12) | 3,744,823,645 | 798 401 208 | 50 972 588 |
| Битләр | 52,146,011 | 6 419 295 | 366 988 |
| Биткә үзгәрешләр | 18.98 | 17,26 | 7,80 |
| Катнашучылар (ноябрь) | 414,442 | 45,936 | 116 |
| Идарәчеләр | 1,119 | 83 | 8 |

# Уңыш критерие?

Татар телле белешмә-энциклопедик контентка мөрәҗәгатьләр санының Татарстанның бар ММЧ һәм башка эре порталларныкыннан югарырак булуы.

*Татарстан:*
*Россиянең 1/3 татарлары*
*Дөньяның ¼ татарлары*

*Тат. Википедия статистикасын күзәтү үзәге*
*w.wiki/qn3*

# Нәрсә этәрә сезне?

Үсештәге тел гадәттә көндәлек тормышының бар мохитләрендә аралашу өчен кулланыла. Телне берәр фән яки сәнгать өлкәсе, җитештерү яки хезмәтләр күрсәтү тармагында кулланмау – ягъни фикерләү рәвешләрен тудыруны чикләү – телгә зур яра ясау, юкка чыгуын якынайтучы гамәл була ...

[Кешеләрнең дөнья турындагы] яңалыкларны бу телдәге тәгъбирләрдән көтүләренә ашкынырга кирәк.

Гайнулла Ф. Шайхиев

# Кереп алыйк?!

Викитөрләр
Викикитап
Викимәгълүмат
Викимания
Викиөзек
Викисүзлек

Башка телләрдә

Авар
Azərbaycanca
تۆرکجه
Башҡортса
Нохчийн
Qırımtatarca
Чӑвашла
Deutsch
English
Español
Euskara
Français
Gagauz
Italiano
Qaraqalpaqsha
Қазақша
Къарачай-малкъар
Кыргызча
Мокшень
Олык марий
Македонски
Кырык мары
Эрзянь
Polski
Русский
Саха тыла
Svenska
Türkmençe
Türkçe
Тыва дыл
Удмурт
ئۇيغۇرچە / Uyghurche

**Бу көнне ... (16 декабрь)**

Бангладеш һәм Һиндстанда — *җиңү*, Бәхрәйндә — *милләт*, Бразилиядә — *хәрби резервистлар*, Казакъстанда — *бәйсезлек*, Көньяк Африка Җөмһүриятендә — *дуслашу*, Непалда — *конституция*, Панамада — *лояльлек*, Таиландта — *милли спорт көне*

- 1775 — инглиз әдәбияты классигы Джейн Остин туа.
- 1902 — шагыйрь Әхмәт Ерикәй дөньяга килә.
- 1954 — мәшһүр татар композиторы Салих Сәйдәшев бакыйлыкка күчә.
- 1963 — алман тарихчысы, тюрколог Герхард фон Менде вафат.
- 1991 — БМО үзенең 1975 елда кабул ителгән сионизмны расизмга тиңләгән карарны кире кага.

*Башка вакыйгалар • Үзгәртү • Проект • Яңартырга*

**Сайланган мәкалә**



***Тукай аһәңнәре*** — җиде Тукай шигыренә язылган вокаль-симфоник поэма.

Бөек Габдулланың бакый булуның 90-еллыгына багышланып, традицион булмаган камера оркестры һәм тавыш башкару өчен 1975 елда Алмаз Монасыйпов тарафыннан языла. Әсәр татар мөнәҗәтләре-бәетләре, инкыйлабка кадәрге чорга хас көйләп-сөйләү алымы h.б. татар һәм гомум Шәрыкъ музыкасы үзенчәлекләренә таяна, үзенә *Тәфтиләү*, *Пар ат* татар халык көйләре өзекләрен ала.

1976 елда Татарстан китап нәшриятында баритон тавышы һәм фортепиано өчен транскрипциясе дөнья күрә. Эмиль Җәләлетдинов һәм Идрис Газиев башкаруында танылган. Әсәрнең алты кисәге татар телендә, берсе татар яки иске татар әдәби телендә башкарыла ала. *↪ Дәвамы*

*Архив • Кандидатлар • Үзгәртү*

**Сез беләсезме?**





- Казакъ ханының ССРБда беренче язу машинасын ясаган оныкчыгы 30 ел гомерен сөргендә үткәрә.
- Керәш буенча дөнья чемпионы күп санлы сабантуйларда баш батыр калып, 50 автомобиль яулый.

**Википедия үз эчтәлегенең "дөрес булуы турында гарантия бирми"**


Википедиянең Интернетта яшәвенә ярдәм итүче *Викимедиа фонды*, проект чикләрендә тупланган мәгълүматлар арасында хаталарның булуы өчен җаваплы түгел. Шәхси кертемнәре өчен җаваплылык катнашучыларда кала.

**Катнашу**

- **Катнашырга:** Нигез тәртипләр һәм башка кагыйдә-киңәшләр белән танышып алыгыз, һәм вики-этикетны хөрмәт итегез; теркәлү *киңәш ителә*, әмма мәҗбүри түгел.
- **Ярдәм кирәк:** Ярдәм битләрне карап чыгыгыз, анда хәл ителмәгән сорауларны исә булышу үзәгебездә сорагыз; теркәлгән катнашучылар *ярдәм курсәтергә әзерлеген* белдергәннәре арасыннан актив волонтёрларга мөрәҗәгать итеп, остаз булулары турында сорый алалар.
- **Кочләрегезне тикшерергә:** Өйрәну урынында үзгәртүләр кертеп карагыз яки мәкаләләрне язу / төзәтү киңәшләре белән танышыгыз.
- **Акча белән ярдәм итү:** Википедия укучылары ясаган иганәләре аркасында энциклопедиябез тулысынча бушлай һәм рекламадан азат. ***Иганәгез*** аны үстерергә һәм ирекле булараk сакларга ярдәм итә ала.
- **Википедия турында фикерләр:** Нәрсә уйлаганыгызны белдерегез - Facebook / VK.com / Telegram.
- **Русия Федерациясе буенча илкүләм Викимедиа оешмасы** ВМРУ (мета) һәм аның коллегалары уздыра торган онлайн һәм *офлайн вакыйгалары*
- **Бөтендөнья Викимедиа җәмгыятьләреннән** күптелле хезмәттәшлекләрендә вәкилебез *"Татар телле викимедиачылары" төркеме* (мета) оештыра торган вакыйгаларда катнашу.

**Җәмгыять**

# Нәрсәгез бар?



# Игътибарга лаеклылары

Сәләт ВикиМәктәбе
Ирекле лицензияләр
Википедия @ Белем җәүһәрләре
ЮНЕСКО XXI гасыр мәгълүмати сәләтләре
Татарстанның бар музейларын Лувр белән бер тактага w.wiki/R7g

*Россия белән таныш*
*Татар 4.0*
*Россия хатын-кызлары*
*Вики-яз*
*Төрки марафон*
*Энциклопедик үзәк*
*Азия ае*
*Безнең университетлар*
*Минем Татарстан*

# Сәләт ВикиМәктәбе



IT BILER FORUM 2019 катнашучылары «Эчтәлекне тәрҗемә итү» вики-коралы белән таныша

# XXI гасыр мәгълүмати сәләтләре

WIKIMEDIA
РОССИЯ

WIKIMEDIA

Викимедиа җәмгыятенең
татар телле катнашучылары
төркеме

**Белем бирү, белемнәрне үзләштерү һәм үстерү процессында Викимедиа ресурсларының роле һәм урыны**

Абдулла А. Хәмидуллин
Байлар Сабасы, 18.10.2019
**w.wiki/AG6**

Берничә публик чыгыш ясадык

*«Челтәребезгә кергән 12000ләп мәктәптә һәрбер укытучы һәм баланың Викимедианың мәгариф өлкәсендәге проектларда катнашуын теләр идем!»*

*Сабин Детцель, ЮНЕСКО белән ассоциацияләнгән мәктәпләр координаторы, Париж*

# «Минем Татарстан»



Тат.Википедиядә
Татарстан географиясе,
мәдәнияте, тарихы
һәм бүгенге
чынбарлыгы турында
мәкаләләр язу
вики-марафоны

Беренчесе
15.12.2020 —
31.01.2021
уза

Вики-хәбәр
w.wiki/rpc

# «Татар 4.0»

**قزان**

**21.02 — 15.04.2019**

w.wiki/pDz

**Jaꞑa əlifвa**

**21.02 — 15.04.2020**


w.wiki/MFe

мин татарча сөйләшәм!

**21.02 — 15.04.2021**


**көтелә**

# Алга таба планнар




Президент грантлары фонды (ФПГ) акчаларына бастырылган Россия юуйлары өчен методик әсбабын (w.wiki/HPv) татар теленә тәрҗемә һәм адаптация

ФГОС дәүләт мәгариф стандартлары буенча төрле дисциплиналарны өйрәтү программасына кертелгән терминнар буенча татар телле вики-контентны тудыруга мәгариф институтларын һәм җәмәгатьчелекне җәлеп итү (чит ил коллегаларының үрнәге буенча)



# Хыялларыгыз?

«Кеше баштан аякка кадәр түгел, баштан күккә кадәр үлчәнә.»
*Конфуций*

«Ил кадерен белим дисәң,
Чит илләрдә йөр икән.»
*Резеда Вәлиева*

«Артык зур вәгъдәләр ышанычны киметә.»
*Цицерон*

*Викиөзек*
*tt.wikiquote.org*

# Кемнән үрнәк аласы?




Урдиайн башлангыч мәктәбе яңа Википедия рекордын куйды — w.wiki/rpj

# Татарстанда яклау?

- Республика Президенты
- Дәүләт Киңәшчесе
- Татар теле буенча комиссия
- Татарстан Дәүләт Советы
- Министрлыклар һәм ведомстволар
- Җәмәгатьчелек, ММЧ

** Иҗтимагый хәбәрдарлыкны үстерү*

** Вики өлкәсендә белем-сәләтләрне тапшыру*

** Википедиядә татар телле контентны үстерү*

** Вики-волонтёрлар керткән өлешен тану*

# Юл харитасы?

Викимедиа платформаларының мөмкинлекләре
* тел мохитен саклау һәм үстерү
* телгә һәм мәдәнияткә бәйле контентның киң тарату һәм кулланылышка кертү
* сезнең яки сезнеңчә кызыклы булган иҗтимагый яктан файдалы мәгълүматны популярлаштыру

Контентны тудыру һәм тышкы ресурсларга сылтамаларны өстәү буенча тематик бәйгеләр һәм проектлар

Эзләү системалары һәм ясалма интеллект өчен Викимәгълүмат мөмкинлекләре    һ.б.    w.wiki/nxa

# Иҗтимагый партнёрлар

Сәләт Фонды

Бөтендөнья татар яшьләре форумы

Татнетны үстерү Фонды

Иҗтимагый берләшмәләр

*Иҗат өчен мохит һәм XXI гасыр мәгълүмати сәләтләре*

*татар телле контентны булдыру һәм үстерү*

# Институциональ партнёрлар

Мәгариф институтлары

ТР Фәннәр Академиясе институтлары

Нәшрият һәм ММЧлар

Мәдәният институтлары

Икътисади институтлар

*XXI гасыр мәгълүмати сәләтләре*

*үз эшчәнлекне һәм үз контентны тематик популярлаштыру*

# Дәүләти партнёрлар

Татарстан Президенты

ТР Дәүләт Советы

Халыклар дуслыгы йорты

Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе

*Тотрыклы иҗтимагый һәм этномәдәни мохит*

*Ресурсларны нәтиҗәле куллану*

*Телне саклау*

# Тагын ничек ярдәм итеп була?

Илнең милли-мәдәни мохтариятларны һәм этник тел активистларны Викимедиа проектлары мөмкинлекләре белән таныштыру

Вики-волонтёрларның тематик чыгышларны һәм мастер-классларны үз чаралар программаларына кертү

Киң күләм җәмәгатьчелеккә Викимедиа проектлары асылын танытучы публикацияләр сериясен оештыру

Русча/инглизчә кертелгән таләпләргә әзләгечләр биргән нәтиҗәләрдә җирле телләрдәге релевант контентын да күрсәтү (Израильдә шулай ивритны күрсәтәләр).

# Контактлар

ВИКИМЕДИА
РУ

Викимедиа җәмгыятенең татар телле катнашучылары төркеме

www.wikimedia.ru

Telegram @wikimediaru

w.wiki/AFi


Telegram @wugtat

# Чакыру

** Мәгълүматны интернетта Россия халыклары телләрендә эзләү, уку, язу һәм башкача тудыру*

** Әһәмиятле әйберләрне Википедиядә туган телегездә тасвирлау*

** Викимедиа проектларына илебезнең халыклары телләрендә өлеш кертелүенә теләктәшлек күрсәтү*



# Материалларга сылтамалар



*w.wiki/qT8*

«Вики-Татарстан» проекты презентациясе

Слайдлар, текст һәм сылтамалар